СОВЕТ СУНЧЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Ленина, дом 76,
село Сунчелеево, 423052

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СӨНЧӘЛЕ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ленин урамы, 76 енче йорт
Сөнчәле авылы , 423052

Тел.: (84344) 4-98-24, ОГРН 1061665002080,ОКПО 94318582, ИНН/КПП 1603004776/160301001
E-mail: *Sunch.Aks@tatar.ru,* http://aksubayevo.tatarstan.ru

**КАРАР**

**№ 99** **29.08.2025 ел**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Советының 22.11.2019 елгы 92 номерлы «Җир салымы турында»карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Федераль кануннарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Сөнчәле авыл җирлеге Советы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Советы КАРАРы:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Советының "Җир салымы турында" 22.11.2019 No 92 карарына ( 2021 ел 3 июнь үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

2 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), әлеге абзацта күрсәтелгән җир индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән), эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган кишәрлекләр һәм кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләре;»

2. Әлеге карарны Сөнчәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Аксубай муниципаль районы мәгълүмати сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) "Интрнет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга .

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сөнчәле авыл җирлеге башлыгы И.В. Крайнова